СОВЕТ УРМАНЧЕЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Ленина, д.5, п.Зверосовхоза,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422186

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ УРМАНЧЫ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Ленин ур., 5 нче йорт, Җәнлек совхозы поселогы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422186

тел.(факс): (85563) 2-12-50; e-mail: Urman.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

**Решение** **Карар**

**От 02 октября 2017г** **№ 1-28**

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урманчы авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм аларны куллану буенча җирле референдум үткәрү көнен билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 ел, 12 июнь, 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясының 2 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 ел, 6 октябрь, 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, "Жирле референдум турында» 2004 ел, 23 март, 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Урманчы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 11 статьясы, Урманчы авыл җирлеге башкарма комитетының “Референдум уздыру инициативасы турында” 2017 нче елның 20 че сентябрендә кабул ителгән 46 номерлы карары, Урманчы авыл җирлеге Советының “Референдум уздыру инициативасы турында” 2017 нче елның 20 че сентябрендә кабул ителгән 2-27 номерлы карары, Урманчы авыл җирлеге Советының “Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Урманчы авыл җирлегендә гражданнардан узара салым акчасын җыю һәм куллану кагыйдәләре” 2014 нче елның 15 нче октябрьда кабул ителгән 2-41 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урманчы авыл җирлеге Советы К А Р А Р КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урманчы авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм аларны куллану буенча җирле референдум үткәрү көнен 2017 нче елның 19 нче ноябренә билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урманчы авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган

гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2018 елда 300 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

1. **Торак пункт чикләрендә су белән тәэмин итү, су чыгару оештыру**: Сотово торак пунктында, Берсут торак пунктында, Новый торак пунктында, Кама урман хуҗалыгы торак пунктында -3 шт., Женлек совхозы торак пунктында, Урманчеево торак пунктында- су алу скважинасын эйлэндереп алу; Женлек совхозы торак пунктында су алу манарасы урнаштыру.
2. **Торак пунктлар чикләрендә янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү:**

янгын гидранты җайланмасын сатып алу һәм урнаштыру:
Новый т.п.,Женлек совхозы т.п.,Урманчы т.п-

**3. Торак пункт территориясен төзекләндерүне оештыру (шул исәптән урамнарны яктырту, кече архитектура формаларын урнаштыру һәм тоту):**

Сотово торак пунктында ,Кама урман хуҗалыгы т.п., Новый т.п. урам яктырту лампаларын алыштыру.

Женлек совхозы торак пунктында «һәлак булган сугышчы –җирдәшләргә» һәйкәлен төзү һәм урнаштыру.

« ӘЙЕ » « ЮК »

2. Әлеге карарны муниципаль берәмлек Советының мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен Мамадыш муниципаль районы Урманчы авыл җирлеге башлыгы А.Я.Ильинга йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Урманчы авыл җирлеге башлыгы,
Совет председателе А.Я.Ильин

СОВЕТ
УРМАНЧЕЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ